МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.01.2024 г. Казань № 29/1

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июлендәге 273 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июлендәге 273 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2023 елның 26 октябрендәге 224 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның 1.2.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге «к», «л» абзацлары белән тулыландырырга:

«к) эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хәрби хезмәт үтәгән һәм 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясендә, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә 2022 елның 30 сентябреннән махсус

хәрби операциядә катнашкан һәм (яки) махсус хәрби операция үткәрү чорында күрсәтелгән территорияләрдә аларга йөкләнгән бурычларны үтәүче затлар;

л) сугыш хәрәкәтләре ветераннары»;

2.6 пунктның 2.6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелә торган мәгълүмат:

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаиләнең статусын раслаучы документлар. Сорау «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Цифрлы платформа) җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

интернат-балалар йортында булу турында белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

гражданинны (гражданинның гаиләсен) аз керемле (аз керемле) дип тануны раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуын раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алуны раслаучы документ. Сорау «Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – ГХАТ БДР) җибәрелә;

ата-ананың берсенең үлемен раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

туу турында таныклыкта баланың әтисе турында язуның әни сүзләреннән теркәлүен раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

бала тууын раслаучы, «Атасы» графасында сызык торган документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың тууын (уллыкка, кызлыкка алынуын) раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе. Сорау «Правосудие» дәүләт автоматлаштырылган системасына (алга таба – «Правосудие» ДАС) җибәрелә;

инвалид балага опека, попечительлек билгеләүне раслаучы документ (опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү яки опека һәм попечительлек органының опекун яки попечитель билгеләү турындагы акты). Сорау «Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – «Опека һәм попечительлек» АМС) җибәрелә;

пенсия билгеләү турында белешмә. Сорау Россия Социаль фондының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – РСФ АМС) җибәрелә;

Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яшендәге гражданин статусын алуны раслаучы документ (картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнгән яшькә кадәр биш ел дәвамында). Сорау РСФ АМС җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Сорау РСФ АМС җибәрелә;

физик затларда физик һәм (яки) психологик үсештә кимчелекләр билгеләүне раслаучы документ (эш бирүче тарафыннан билгеләнә). Сорау РСФ АМС җибәрелә;

хәрби билет булуын раслаучы документ. Сорау «Горизонт-МР» гражданнар турында автоматлаштырылган мәгълүмат системасына җибәрелә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында белешмә яки хөкем ителү һәм (яки) җинаять эзәрлекләү факты булу (булмавы) яки җинаять эзәрлекләүләрен туктату турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

качак яки мәҗбүри күченүче статусын раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документ. Сорау «Социаль яклау» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – «Социаль яклау» АМС) җибәрелә.

гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге пунктта күрсәтелгән документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

3.5 пунктның 3.5.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаиләнең статусын раслаучы документлар. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

интернат-балалар йортында булу турында белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

гражданинны (гражданинның гаиләсен) аз керемле (аз керемле) дип тануны раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуын раслаучы белешмә. Сорау Цифрлы платформага җибәрелә;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алуны раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

ата-ананың берсенең үлемен раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

туу турында таныклыкта баланың әтисе турында язуның әни сүзләреннән теркәлүен раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

бала тууын раслаучы, «Атасы» графасында сызык торган документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың тууын (уллыкка, кызлыкка алынуын) раслаучы документ. Сорау ГХАТ БДР җибәрелә;

ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе. Сорау «Правосудие» ДАС җибәрелә;

инвалид балага опека, попечительлек билгеләүне раслаучы документлар (опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү яки опека һәм попечительлек органының опекун яки попечитель билгеләү турындагы акты). Сорау «Опека һәм попечительлек» АМС җибәрелә;

пенсия билгеләү турында белешмә. Сорау РСФ АМС җибәрелә;

Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яшендәге гражданин статусын алуны раслаучы документ (картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнгән яшькә кадәр биш ел дәвамында). Сорау РСФ АМС җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Сорау РСФ АМС җибәрелә;

физик затларда физик һәм (яки) психологик үсештә кимчелекләр билгеләүне раслаучы документ (эш бирүче тарафыннан билгеләнә). Сорау РСФ АМС җибәрелә;

хәрби билет булуын раслаучы документ. Сорау «Горизонт-МР» гражданнар турында автоматлаштырылган мәгълүмат системасына җибәрелә;

ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында белешмә яки хөкем ителү һәм (яки) җинаять эзәрлекләү факты булу (булмавы) яки җинаять эзәрлекләүләрен туктату турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

качак яки мәҗбүри күченүче статусын раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар. Сорау «Социаль яклау» АМС җибәрелә;

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Комиссиядә КУЭ субъектларының гаризасын һәм башка документларын карау һәм кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү.

3.8.1. СӨИҮ хезмәткәре КУЭ субъектларының гаризаларын карау нәтиҗәләре буенча Министрлыкка Комиссия утырышын үткәрү өчен кирәкле материаллар комплектын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар комплекты.

3.8.2. Министрлык документлар комплектын карау өчен җаваплы башкаручыны билгели һәм аңа тәкъдим ителгән материалларны һәм карар проектын тапшыра.

Җаваплы башкаручы Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук комиссия тарафыннан карау өчен материаллар комплектларын формалаштыра.

Гариза бирүчеләр тәкъдим иткән документлар Комиссия каравына теркәлгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча чыгарыла.

Комиссиянең составы һәм аның турындагы нигезләмә Министрлык боерыгы белән раслана.

Комиссияне Рәис җитәкли, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары.

Комиссия утырышлары 1 майдан 20 декабрьгә кадәр айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Карау өчен сораулар булмаган очракта, Комиссия утырышы үткәрелми.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлык белгеченә документлар комплектын тапшыру, Комиссиядә карау өчен материаллар формалаштыру.

3.8.3. Комиссия секретаре:

комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра һәм аны Комиссия рәисенә раслау өчентапшыра;

Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын үткәрү турында хәбәр итә.

Комиссия утырышының көн тәртибе, шулай ук Комиссия утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында Комиссиядә Социаль өлкә инновацияләре үзәгеннән катнаша Комиссия секретаре Комиссия әгъзаларына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Комиссия утырышын үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыру һәм аны Комиссия әгъзаларына юллау.

3.8.4. Комиссия секретаре Комиссиядә карап тикшерүгә тәкъдим ителгән материаллар буенча чыгыш ясый һәм КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану (яисә танудан баш тарту) турында карар проектын игълан итә.

КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану мәсьәләләрен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Министрлыкка КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында карар проектын раслауны тәкъдим итәргә;

Министрлыкка КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар проектын раслауны тәкъдим итәргә.

Комиссия утырышта катнашучылар арасыннан күпчелек тавыш белән карарлар кабул итә. Тавышлар тигез булган очракта, Рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Процедураның нәтиҗәсе: мәсьәләләрне карау һәм карар кабул итү.

3.8.5. Комиссия секретаре тавышларны саный һәм алынган нәтиҗәне игълан итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә.

Комиссия карарлары Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул – Комиссия рәисе тарафыннан, ә ул булмаса – Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

Комиссия секретаре Комиссия утырышы беркетмәсен Министрлык белгеченә җибәрә.

Регламентның 3.8.4-3.8.5 пунктларында билгеләнгән процедуралар Комиссия утырышы уздырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тавышларны санау һәм беркетмә рәсмиләштерү.

3.8.6. Министрлык белгече, беркетмә нигезендә, КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану яисә танудан баш тарту турында Министрлык карарын рәсмиләштерә. Министрлыкның кабул ителгән карары кече яки урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие буларак тану (танудан баш тарту) турында карарларны теркәү журналында теркәлә, аның формасы Регламентка 15 нче кушымта белән билгеләнгән.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә, әмма гариза теркәлгәннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән карар.

3.8.7. КУЭ субъектларын социаль предприятие дип тану (яки танудан баш тарту) турында карарны Министрлык белгече:

шәхси мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә (вәкилгә) кәгазь чыганакта бирә;

гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына гариза бирүчегә юллый;

гариза бирүчегә Республика порталындагы шәхси кабинеты аша хәбәр итә. Процедураларны үтәү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көндә (шәхси мөрәҗәгать иткәндә) яисә алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә (карар электрон почта адресы буенча җибәрелгән очракта) гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында бирелгән (җибәрелгән) карар.

3.8.8. Ел саен, 5 июльдән соңга калмыйча, Министрлык Татарстан Республикасында социаль предприятие статусы булган КУЭ субъектлары исемлеген (алга таба – Исемлек) төзи һәм, КУЭ субъектларының бердәм реестрын алып бару максатларында Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә тапшыра.

КУЭ субъекты тарафыннан, КУЭ субъектын социаль предприятие буларак тану максатларында, гариза һәм Регламентта күрсәтелгән тиешле документлар тапшырылган очракта, 1 июньнән соң, исемлек Министрлык тарафыннан КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында карар кабул ителгән айдан соңгы икенче айның беренче көненә төзелә.

Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала: КУЭ субъектының исеме, салым түләүченең идентификация номеры, 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясының 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән, КУЭ субъектын социаль предприятие дип тануга нигез булган шарт (шартлар). Исемлекнең формасы Регламентка 16 нчы кушымтада китерелгән.

Процедураның нәтиҗәсе: КУЭ субъектларының бердәм реестрында юридик затның яки шәхси эшкуарның социаль предприятие булып торуына күрсәтү.

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры Н.В.Кондратовага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасында
кече һәм урта эшкуарлык
субъектларын социаль
предприятиеләр дип тану
буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

## Гражданинны «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә кертүне раслый торган документлар исемлеге

| Гражданнар категориясе | Документлар (тиешле нигез булганда тапшырыла) |
|---|---|
| Инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар | инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>физик затта физик һәм (яки) психологик үсештәге җитешсезлекләр билгеләнүен раслый торган документ күчермәсе (эш бирүче тарафыннан билгеләнә) |
| Балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар | баланың тууы (уллыкка алынуы, кызлыкка алынуы) турында таныклык күчермәләре;<br>инвалид балага опека, попечительлек билгеләнүен раслый торган документларның (опека яки попечительлек башкарылуы турында килешү яки опека һәм попечительлек органыннан опекун яки попечитель билгеләнүе турындагы акт) күчермәләре;<br>инвалидлык билгеләү («инвалид бала» категориясе билгеләнү) фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>күпбалалы ата-аналар өчен:<br>Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе яисә күпбалалы гаилә статусын раслый торган башка документлар;<br>ялгыз ата-аналар өчен:<br>аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында документ күчермәсе;<br>әти-әнинеңең берсенең үлеме турында таныклык күчермәсе;<br>гражданлык хәле актларын теркәү |

| | |
|---|---|
| | органнарыннан туу турында таныклыкта баланың әтисе турындагы язуның ана сүзенә карап теркәлүе турында күрсәтелгән белешмә;<br>ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе;<br>яңа теркәлгән гаилә булмавын раслаучы документ күчермәсе (яңа гаилә теркәлүе турында тамга булмаган паспорт);<br>баланың туу турында «Атасы» графасында сызыу куелган таныклык күчермәсе |
| Балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>балалар интернат-йортында булу турында белешмә күчермәсе |
| Пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды территориаль органының пенсия таныклыгы күчермәсе яки пенсия билгеләү турында белешмәсе;<br>инвалидлык фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>хәрби билет күчермәсе;<br>гражданинның Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яше (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче алдагы 5 ел двәамында) статусы алуын раслый торган документларның күчермәләре |
| Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар | иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителү турында белешмә яки хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булуы (булмавы) яки җинаять эзәрлекләвен туктату турында белешмә күчермәсе |
| Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр | качак таныклыгы яки мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе |
| Аз керемле гражданнар | гражданинны (гражданинның гаиләсен) аз керемле дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе; |
| Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар күчермәләре |
| Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар | гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе |
| эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы | Россия Федерациясе гражданины паспорты |

| | |
|---|---|
| дәүләт хезмәтендә, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хәрби хезмәт үтәгән һәм 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясендә, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә 2022 елның 30 сентябреннән махсус хәрби операциядә катнашкан һәм (яки) махсус хәрби операция үткәрү чорында күрсәтелгән территорияләрдә аларга йөкләнгән бурычларны үтәүче затлар; | күчермәсе;<br>эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хәрби хезмәт үтүне һәм 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясендә, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә 2022 елның 30 сентябреннән махсус хәрби операциядә катнашуны һәм (яки) махсус хәрби операция үткәрү чорында күрсәтелгән территорияләрдә аларга йөкләнгән бурычларны үтәүне раслый торган белешмә күчермәсе |
| Сугыш хәрәкәтләре ветераннары | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>сугыш хәрәкәтләре ветераны таныклыгының күчермәсе |